КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 5 март г.Казань № 137

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

Үсемлекчелекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

Савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән өлкәнрәк кәҗәләрне карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплау өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен.».

әлеге карарга Үсемлекчелекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен һәм Савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән өлкәнрәк кәҗәләрне карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплау өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (карарга теркәләләр) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 5 март, 137 нче
карары редакциясендә)

Үсемлекчелекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип түбәндәгеләргә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан башка), шулай ук эшчәнлеген кимендә бер календарь ел гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр, алучылар) бирү механизмын билгели:

а) агротехнология эшләре комплексын үткәрүгә, авыл хуҗалыгы җитештерүенең экология иминлеге дәрәҗәсен күтәрүгә, шулай ук авыл хуҗалыгы культуралары үсә торган чәчү мәйданнарында туфракларның уңдырышлылыгын һәм сыйфатын яхшыртуга (алга таба – үсемлекчелек өлкәсендә булышлык күрсәтү);

б) яшелчәләрне ябык грунтта җитештерүгә (алга таба – яшелчәләрне ябык грунтта стимуллаштыру);

в) зыян сала торган объектлар (корткычлар, чүп үләннәре һәм авырулар) белән зарарлану рискларын киметү өчен авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләренә фитосанитария тикшерүен үткәрүгә (алга таба – чәчүлекләргә фитосанитария тикшерүен үткәрү).

2. Субсидияләр бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Субсидияләр алучыларны сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм реализацияләү эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

алучыларның агымдагы финанс елында авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнары булуы.

4. Субсидия алучы субсидия бирү турында килешү төзергә планлаштырыла торган көнгә кадәр 15 эш көненнән дә иртәрәк булмаган көнгә түбәндәге таләпләргә туры килгән очракта, субсидия бирелә:

законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм җитештерү эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырган;

субсидия алучы – юридик зат үзгәртеп оештыру, ябу, банкротлык процессында тормаган, ә субсидия алучы – индивидуаль эшмәкәр үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмаган;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия юридик заты (аларның устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән раслана торган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булган чит ил юридик затларның катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан артыграк булган) булып тормаган;

бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмаган;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән башка бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаган.

5. Үсемлекчелек өлкәсендә ярдәм күрсәтү өчен субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = П \times 60{,}0,$$

монда:

W – үсемлекчелек өлкәсендә булышлык күрсәтү өчен алучыга бирелергә тиешле субсидия күләме;

П – агымдагы финанс елында алучының булган авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнары, гектар;

60,0 – 1 гектар чәчүлек мәйданына субсидиянең минималь ставкасы, сум.

6. Яшелчәләрне ябык грунтта җитештерүне стимуллаштыру өчен алучыга субсидия хисап финанс елы өчен үсемлекчелек продукциясен җитештерү, аларның чыгымнары, үзкыйммәте һәм аларны реализацияләү турында рәсми статистик хисап формалаштырылган мәгълүмат һәм (яки) хисап финанс елы өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларының җитештерү эшчәнлеге турында мәгълүмат (алга таба – хисап елы өчен еллык хисап) нигезендә 1 кв.метр чәчүлек мәйданына 10,0 сум исәбеннән чыгып бирелә.

7. Чәчүлекләргә фитосанитария тикшерүен үткәрү өчен алучыга субсидия 1 гектар тикшерелгән чәчүлек мәйданына 150,0 сум исәбеннән чыгып бирелә.

8. Бу Тәртипнең 5 – 7 нче пунктларында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен алучылар Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарәләр) түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча, үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, шул исәптән түбәндәгеләр турында мәгълүматы булган субсидия бирү турында гариза:

субсидия алучы законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлү һәм җитештерү эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру;

субсидия алучы – юридик зат үзгәртеп оештыру, ябу, банкротлык процессында булмау, ә субсидия алучы – индивидуаль эшмәкәр үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмау;

субсидия алучы чит ил юридик заты, шулай ук Россия юридик заты (аларның устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән раслана торган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булган чит ил юридик затларның катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан артыграк булган) булып тормау;

субсидия алучы бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокук актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау;

субсидия алучының субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмавы;

алучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавы;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча бирелергә тиешле субсидияләр турында белешмә кәгазе – исәп-хисап.

Субсидияләр алучылар үз теләге белән алучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган салым органы белешмә кәгазен кертергә хокуклы. Әгәр дә әлеге документ субсидия алучы тарафыннан үз теләге белән кертелмәгән булса, Министрлык аны салым органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә соратып ала.

Тапшырылган документларның күчермәләре алучы тарафыннан раслана.

9. Бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен алучылар Идарәгә түбәндәгеләрне өстәмә тапшыра:

агымдагы финанс елында алучыда булган авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнары турында мәгълүмат (гектарларда);

эшчәнлеген кимендә бер календарь ел гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы оешмалары өчен – оешманы ачу көне турында мәгълүмат.

10. Бу Тәртипнең 6 нчы пунктында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен алучылар Идарәгә хисап елы өчен еллык хисапны өстәмә кертә.

11. Бу Тәртипнең 7 нче пунктында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен алучылар Идарәгә чәчүлекләргә фитосанитария тикшерүен үткәрү буенча башкарылган эшләр актын өстәмә кертә.

12. Идарәләр:

субсидияләр бирү турындагы гаризаларны алар кергән көнне (нумерлана, шнурлана торган һәм мөһер сугып тоташтырыла торган) журналда терки;

гаризаны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә:

тапшырылган документларның бу Тәртипнең 8 – 11 нче пунктларына туры килү-килмәвен карап тикшерә һәм субсидиядләр бирү турында яки субсидияләр бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

әлеге документлар нигезендә Министрлык тарафыннан расланган форма буенча алучылар яктылыгында Татарстан Республикасының муниципаль районына бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма беләшмә кәгазьләрен – исәп-хисапларын төзи һәм аларны субсидия бирү турында карар кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә Министрлыкка кертә;

Россия Федерациясенең Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган формалар буенча һәм Министрлык тарафыннан билгеләнә торган вакытларда алучыларның финанс-икътисадый хәле турындагы җыелма хисаплылыкны Министрлыкка кертә;

алучылар белән Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә субсидия бирү турында килешүләр төзи.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр – түбәндәгеләр:

документларны тулы булмаган комплектта тапшыру һәм алар бу Тәртипнең таләпләренә туры килмәү;

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүмат дөрес булмау;

бюджет йөкләмәләре лимиты булмау.

Бюджет йөкләмәләре лимиты җитәрлек булмаган очракта, субсидияләр гаризаларны тапшыру чираты тәртибендә бирелә.

Субидияләрне бирүдән баш тарткан очракта, Идарә бу пунктның өченче абзацында күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә алучыга баш тарту турында хәбәрнамә җибәрә.

13. Субсидия бирү турындагы килешүдә түбәндәгеләр күздә тотыла:

а) субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турындагы хисаплылыкны һәм Министрлык тарафыннан билгеләнгән башка хисапларны бирү формасы һәм вакытлары;

б) субсидия алучының (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый оешмалар катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерция оешмаларыннан башка) Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары тарафыннан субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен субсидия алучы үтәвен тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

в) Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча аны бирү максатларын,

шартларын һәм тәртибен бозу фактлары билгеләнгән очракта, субсидияләрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару тәртибе.

14. Субсидия бирү нәтиҗәлелегенең күрсәткече – түбәндәгеләр:

бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән субсидияне алу өчен авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданы;

бу Тәртипнең 6 нчы пунктында күрсәтелгән субсидияне алу өчен ябык грунттагы яшелчәләр мәйданы;

бу Тәртипнең 7 нче пунктында күрсәтелгән субсидияне алу өчен авыл хуҗалыгы культураларының тикшерелгән мәйданы.

15. Министрлык Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып тора һәм алучылар яктылыгында Татарстан Республикасының муниципаль районы буенча биреләргә тиешле субсидияләр турында җыелма белешмә кәгазьләрен – исәп-хисапларны Идарәләр керткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә акчаны Татарстан Республикасының Финанс министрлыгында ачылган үз шәхси исәбеннән Идарәләрнең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлекләрендә ачылган шәхси исәпләренә күчерүне гамәлгә ашыра.

Идарәләр тарафыннан алучылар яктылыгында Татарстан Республикасының муниципаль районы буенча биреләргә тиешле субсидияләр турында Министрлыкка кертелгән җыелма белешмә кәгазьләре – исәп-хисаплар субсидияләрне күчерү өчен нигез булып тора. Идарәләр бюджет акчасын үз шәхси исәбенә алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә алучыларның исәп-хисап исәпләренә субсидияләрне күчерә.

16. Бирелгән субсидияләр, Министрлык һәм вәкаләтле дәүләт финанс тикшерүендә тоту органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча бу Тәртип һәм субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнә торган тәртипне һәм шартларны бозу фактлары ачыкланган очракта, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта, Идарәнең тиешле таләбен алган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә бюджет законы нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

17. Бу Тәртипнең 16 нчы пунктында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Министрлык тарафыннан законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

18. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

19. Идарәләр тарафыннан Министрлыкка һәм алучылар тарафыннан Идарәләргә кертелә торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык тиешле вазыйфаи затларга һәм җитәкчеләргә йөкләнә.

20. Бюджет акчасын файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

_______________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 5 март, 137 нче
карары редакциясендә)

Савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән өлкәнрәк кәҗәләрне карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплау өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән өлкәнрәк кәҗәләрне карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплау өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Субсидияләрне алу өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарны сайлап алу критерийлары – түбәндәгеләр:

шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу буенча хуҗалык кенәгәсендә законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән булу һәм эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру;

агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу буенча хуҗалык кенәгәсендәге язулар нигезендә савым сыерлары, ана кәҗәләр һәм бер яшьтән өлкәнрәк кәҗәләрнең баш саны булу.

4. Субсидияләр алучыларның субсидия бирү планлаштырыла торган айга кадәр килә торган айның беренче көненә бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучылар булып тормау шарты белән субсидия шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга бирелә.

5. Субсидия агымдагы финанс елының беренче гыйнварына түбәндәгеләр булган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга бер тапкыр бирелә:

бер савым сыеры өчен – 1 баш санына 2 000 сум күләмендә;

ике савым сыеры өчен – 1 баш санына 3 000 сум күләмендә;

өч һәм аннан да күбрәк савым сыеры өчен – 1 баш санына 4 000 сум күләмендә.

Ана кәҗәләр һәм бер яшьтән өлкәнрәк кәҗәләр өчен субсидия бер баш санына 1 000 сум исәбеннән чыгып бирелә.

6. Субсидия алу өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар авыл яки шәһәр җирлегендәге башкарма комитетка (алга таба – башкарма комитет) Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча, түләү реквизитларын, почта адресын, савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән өлкәнрәк кәҗәләрнең баш санын, киләсе финанс елының беренче гыйнварына кадәр савым сыерлары, ана кәҗәләр һәм бер яшьтән өлкәнрәк кәҗәләрнең баш санын саклап калу йөкләмәләрен күрсәтеп, шул исәптән түбәндәгеләр турында мәгълүматы булган субсидия бирү турында гариза тапшыра:

субсидия алучы бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормау;

субсидия алу һәм субсидия бирү турында документларны карап тикшерүдә катнашучы затлар файдалана алу өчен бирелгән шәхси мәгълүматларга караган мәгълүматны эшкәртүгә ризалыгы.

7. Башкарма комитет (килешү буенча):

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның субсидия бирү турындагы гаризаларын алар кергән көнне (нумерлана, шнурлана торган һәм мөһер сугып тоташтырыла торган) журналда терки;

гаризаны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә:

тапшырылган документларның бу Тәртипнең 6 нчы пунктына туры килү-килмәвен карап тикшерә;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча савым сыерлары, ана кәҗәләр һәм бер яшьтән өлкәнрәк кәҗәләрнең баш саны булу-булмавын раслый торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу буенча хуҗалык кенәгәсеннән күчермәне булдыра һәм аны раслый;

Министрлык белән расланган форма буенча шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга бирелергә тиешле субсидияләр турында белешмә кәгазен – исәп-хисабын рәсмиләштерә;

тапшырылган документларны Министрлыкның тиешле муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) җибәрә.

Субсидия бирү турындагы гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен бу Тәртип шартларына шәхси ярдәмче хуҗалык туры килмәү нигез булып тора.

8. Идарә:

бу Тәртипнең 7 нче пунктында күрсәтелгән документларны башкарма комитеттан алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә:

тапшырылган документларның бу Тәртипнең 6 нчы һәм 7 нче пунктларына туры килү-килмәвен карап тикшерә һәм, субсидияләр алучыларын, субсидияләр күләмен һәм баш тартуның нигезләмәсен (субсидия бирүдән баш тартылган очракта) күрсәтеп, боерык рәвешендә рәсмиләштерелә торган субсидиядләр бирү турында яки субсидияләр бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

әлеге документлар нигезендә Министрлык тарафыннан расланган форма буенча Татарстан Республикасының муниципаль районына бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма беләшмә кәгазьләрен – исәп-хисапларын төзиләр һәм субсидия бирү турындагы карарны кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә Министрлыкка кертәләр.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр – түбәндәгеләр:

документларны тулы булмаган комплектта тапшыру һәм алар бу Тәртипнең таләпләренә туры килмәү;

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүмат дөрес булмау;

бюджет йөкләмәләре лимиты булмау.

Бюджет йөкләмәләре лимиты җитәрлек булмаган очракта, субсидияләр гаризаларны тапшыру чираты тәртибендә бирелә.

Субидияләрне бирүдән баш тарткан очракта, Идарә бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга бу турыда хәбәрнамә җибәрә.

9. Субсидия бирү нәтиҗәлелегенең күрсәткече булып субсидия бирү елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына кадәр савым сыерлары, ана кәҗәләр һәм бер яшьтән өлкәнрәк кәҗәләрнең баш санын саклап калу тора. Министрлык тарафыннан расланган форма буенча нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турындагы хисап агымдагы финанс елының 1 июле хәленә карата агымдагы финанс елының 15 июленә кадәр һәм субсидия бирү елыннан соң килә торган елның 1 гыйнвары хәленә карата субсидия бирү елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Идарәгә башкарма комитет тарафыннан кертелә.

Баш санын саклап калу турында кабул ителгән йөкләмә вакыты чыкканга кадәр авыру аркасында савым сыерлары, ана кәҗәләр һәм бер яшьтән өлкәнрәк кәҗәләр үлгән яки аларны мәҗбүри рәвештә чалган очракта, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар башкарма комитетларга ветеринария белешмә кәгазьләрен һәм мал-туарны бракка чыгару актларын билгеләнгән тәртиптә кертә.

10. Министрлык Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып тора һәм алучылар яктылыгында Татарстан Республикасының муниципаль районы буенча бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма белешмә кәгазьләрен – исәп-хисапларны Идарәләр керткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә акчаны Татарстан Республикасының Финанс министрлыгында ачылган үз шәхси исәбеннән Идарәләрнең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлекләрендә ачылган шәхси исәпләренә күчерүне гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасының муниципаль районы буенча бирелергә тиешле субсидияләр турында Идарәләр тарафыннан Министрлыкка кертелгән җыелма белешмә кәгазьләре – исәп-хисаплар субсидияләрне күчерү өчен нигез булып тора. Идарәләр бюджет акчасын үз шәхси исәбенә алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга кредит оешмаларында ачылган шәхси исәпләргә субсидияләр күчерә.

11. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртип белән билгеләнгән тәртипне һәм аларны бирү шартларын бозу фактларын ачыкланган очракта, шулай ук Министрлык һәм вәкаләтле дәүләт финанс тикшерүендә тоту органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча Идарәнең тиешле таләбен алган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә бюджет законы нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

12. Бу Тәртипнең 11 нче пунктында күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Министрлык тарафыннан законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

15. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

16. Башкарма комитетлар тарафыннан Идарәгә, Идарәләр тарафыннан Министрлыкка һәм шәхси ярдәмче хуҗалык тарафыннан башкарма комитетка кертелә торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык тиешле вазыйфаи затларга, җитәкчеләргә, шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып баручы гражданнарга йөкләнә.

17. Бюджет акчасын файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

___